# <u>Товарны кире кайтару һәм алыштыру</u>

**1. Сату-алу килешүен үтәүдән баш тартып, товар өчен түләнгән акчаны кире кайтаруларын таләп итү турында язма гариза яки сыйфатсыз товарны алыштыру турында язма гаиза (таләп) языгыз**

Кулланучы товарда җитешсезлекләр таба икән, ул хокуклы:

- товарны шундый ук маркадагы товарга алыштыруларын таләп итәргә;

- товарны, сатып алу бәясен кабат исәпләп, башка маркадагы шундый ук товарга алыштыруларын таләп итәргә;

- сату-алу килешүен үтәүдән баш тартып, товар өчен түләнгән акчаны кире кайтаруларын таләп итәргә.

*Гариза ирекле формада языла, анда гариза язучының ФИОсы, адресы, товарның җитешсезлеге күрсәтелә, сату-алу килешүен үтәүдән баш тарту һәм товар өчен түләнгән акчаны кире кайтаруларын таләп итү турындагы (товарны тиешле сыйфаттагы шундый ук товарга алыштыруны сорау турындагы) гариза*.

Гаризада сез сатучыдан экспертиза билгеләнгән очракта сезгә хәбәр итүләрен һәм анда катнашуга чакыруларын сорый аласыз.

Сез әлеге таләпләрне *гарантия срогы вакытында яки товарның яраклылык вакыты беткәнче*, әгәр дә андый чикләр билгеләнмәгән икән, товарны сатып алганнан соңгы *ике ел* эчендә куя аласыз.

Әгәр дә товар техник яктан катлаулы, мисалга, автомобильләр, мотоцикллар, система блоклары, компьютерлар, ноутбуклар һәм башкалар икән, сез товар өчен түләнгән акчаны кире кайтаруларын яки товарны сатып алганнан соңгы 15 көн эчендә товарны тиешле сыйфаттагы шундый ук товарга алыштыруларын таләп итәргә хокуклы.

<u>*Әлеге срок узганнан соң*</u> сез шулай ук таләпләрегезне белдерергә хокуклы, әмма инде аерым очракларда гына:

- *товарда зур җитешсезлекләр ачыкланса;*

- *сатучы тарафыннан товардагы җитешсезлекләрне бетерүнең законлы сроклары бозылу очрагында;*

- товардагы җитешсезлекләрне берничә тапкыр бетерү аркасында *товарны елына гомумән алганда 30 көннән артыграк файдалану мөмкин булмаганда*.

## 2. Гариза (шикаять) күчермәсенә аны сатучы кабул итүе турында билге (штамп) куйдырыгыз

*Сатучы сездән гаризаны (шикаятьне) , шулай ук сыйфатсыз товарны кабул итеп алырга* һәм кирәк булган очракта кире кайтарылган товарның сыйфатын тикшереп карарга бурычлы.

## 3. Товарга экспертиза ясауда катнашыгыз

Товарда җитешсезлекләр килеп чыгу сәбәпләре турында бәхәс туган очракта *сатучы товарга экспертизаны үз хисабына ясый.*

Сез экспертиза ясауда катнашырга хокуклы. Килешмәгән очракта *экспертларның нәтиҗәләренә суд тәртибендә шикаять белдерергә була.*

Әгәр дә экспертиза нәтиҗәләре буенча товарда җитешсезлекләр стаучы гаебе белән килеп чыкмаганлыгы ачыкланса, *сез сатучыга экспертизага һәм товарны саклау һәм транспортлауга киткән  чыгымнарны кире кайтарырга* тиеш буласыз.

## 4. Сыйфатсыз товар өчен акча алыгыз яки сыйфатсыз товар урынына яңа шундый ук товар алыгыз

Сыйфатсыз товар өчен түләнгән акчаны кире кайтару срогы акчаны кире кайтару турындагы таләп кергәннән соң *10 көн* тәшкил итә.

Сатып алучыга товар өчен түләнгән акчаны кире кайтарганда *сатучы аннан товарны тулысынча яки өлешчә файдаланган өчен, товарның товар рәвеше югалган  яки шундый хәлләр өчен аның бәясе киму хакын тотып калырга тиеш түгел*.

Сыйфатсыз товар яңасына аны алыштыру турында таләп кергәннән соңгы *7 көн* эчендә алыштырылырга тиеш.

Кире кайтарыла торган товарның сыйфатына *өстәмә тикшерү кирәк булганда* сатучы товарны аны алыштыру турында таләп кергән көннән *20 көн* эчендә алыштырырга тиеш.

Әгәр дә товарны алыштыру турында таләп кергән вакытка *шундый ук товар* булмаса, аны таләп кергән көннән *бер ай эчендә* алыштыралар.

Әгәр дә товарны алыштыру өчен җиде көннән артыграк вакыт таләп ителсә*, сез товарны алыштыру вакытына шундый ук товар биреп торуларын таләп итәргә хокуклы.* Техник яктан катлаулы товарлар, мисалга, автомобиль, мебель, көнкүреш техникасы товарлары, гражданлык кораллары һәм РФ Хөкүмәте карары белән билгеләнгән башка товарлар искәрмә булып тора.

## 1. Сыйфатсыз товарны сатучыга кире кайтарыгыз

Товар өчен түләнгән акчаны кире кайтару таләп ителгән сату-алу килешүен гамәлгә ашырудан баш тарткан очракта *сатып алучы сатучы таләбе буенча һәм аның хисабына сыйфатсыз товарны кире кайтарырга тиеш.*

Сатып алучы тарафыннан сатучыга сыйфатсыз товарны алыштыру турында таләп куелганнан соң сатып алучы тарафыннан товарны кире кайтару вакыты закон белән билгеләнмәгән, бу сатып алучының сатучы аны сыйфатлы товарга алыштырганчыга кадәр сыйфатсыз товарны кире кайтармый торыргы хокуклы булуы белән бәйле.

Сатып алучылар сыйфатын тикшереп экспертиза уздыру өчен товарны сатучыга бирергә тиешләр.

## 2. Сатучы (товар җитештерүче) мәсьәләне ирекле тәртиптә хәл итмәгән очракта судка мөрәҗәгать итегез

*Сыйфатсыз товар өчен түләнгән акчаларны кире кайтару яки товарны алыштыру турындагы* иск таләпләреннән кала, сез сатучыдан өстәмә рәвештә сыйфатсыз товар сату белән бәйле рәвештә сезгә китерелгән *барлык чыгымнарны да каплауны* таләп итә аласыз.

Әгәр дә сатучы акчаны кире кайтару срогын бозган икән, аннан сезнең файдага акчаны кире кайтару срогы чыкканнан соңгы һәр көн өчен товар бәясенең бер проценты күләмендә неустойка түләтә аласыз.

Кулланучылар хокукларын яклау буенча исклар белән мөрәҗәгать итүчеләр, әгәр дә иск бәясе 1 000 000 сумнан артмаса, *дәүләт пошлинасын түләмиләр.*

Сатучы тарафыннан ирекле рәвештә канәгатьләндерелмәгән таләпләрнең суд аша канәгатьләндерелүе очрагында суд сатучыдан кулланучы файдасына суд тарафыннан кулланучы файдасына чыгарылган суммадан *50 процент күләмендә* штраф түләттерә.

Иск канәгатьләндерелгән очракта суд сезнең ходатайство буенча җаваплы заттан *суд чыгымнарын, шул исәптән вәкил хезмәтләренә түләү чыгымнарын тулысынча яки өлешчә каплаттырырга мөмкин*.

***Мөһим!***

*Кулланучылар хокуклары бозылу белән бәйле рәвештәге түләүләр һәм штрафлар салымнан азат ителми. Мораль зыян өчен түләнә торган акчалата компенсациягә салым салынмый.*

**Файдалы сылтамалар:**

Кулланучыларның хокукларын яклау һәмкеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек Федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе сайты - http://16.rospotrebnadzor.ru/

**Сатучыга сату-алу килешүен өзү һәм СЫЙФАТСЫЗ товар өчен түләнгән акчаны кире кайтару турында шикаять үрнәге**

Кемгә: ______________________
*(шәхси эшкуарның ФИОсы/оешманың атамасы)*

______________________
*(шәхси эшкуарның /оешманың адресы)*

Кемнән: ______________________
*(сатып алучының ФИО)*

______________________
*(сатып алучының почта адресы)*

______________________
*(элемтә өчен телефоны)*

ШИКАЯТЬ

____________________ мин сезнең оешмада сатып алдым ____________________________.
*(сатып алу датасы)* *(товарның тулы атамасы)*
Шикаятькә чекның һәм сату-алу килешүе (булганда[1]) күчермәләрен беркетәм.
Товарны сатып алганнан соң, әлеге товарның түбәндәге сәбәпләр аркасында сыйфатсыз булуы ачыкланды:_______________________________________________________________
*(сатып алынган товарның сыйфатсыз дип табылуына күрсәтә торган сәбәпләрне күрсәтегез)*
“Кулланучыларның хокукларын яклау турында” Законның 18 статьясының 1 пункты нигезендә товарда җитешсезлекләр табылган очракта гарантия вакыты чыкканчыга кадәр мин сату-алу килешүенең өзелүен һәм товар өчен түләнгән акчаның кире кайтарылуын таләп итә алам.

---
[1] *В соответствии с п. 5 ст. 18 Закона «О защите прав потребителей» отсутствие кассового или товарного чека либо иного документа удостоверяющего факт и условия покупки товара, не является основанием для отказа в удовлетворении требований.*

Житешсезлекләр товарга гарантия вакыты чыкканчы ачыклану сәбәпле, сату-алу килешүен өзүегезне һәм товар өчен ___________________________ сум күләмендә түләнгән акчаны таләп куелганнан соңгы 10 көн эчендә кайтаругызны сорыйм (“Кулланучыларның хокукларын яклау турында” Законның 22 статьясы нигезендә).

Минем таләпләр үтәлмәгән очракта мин судка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булачакмын. Иск гаризасында, югарыда әйтелгәннәрдән тыш, мин судтан Сезнең оешмадан мораль зыян өчен компенсация түләттерүләрен дә сораячакмын. Моннан тыш Сезгә дәүләт пошлинасын һәм сатып алучының таләпләрен ирекле тәртиптә үтәмәгән өчен штраф түләргә дә туры киләчәк (“Кулланучыларның хокукларын яклау турында” Законның 13 статьясының 6 пункты буенча).

Кушымталар:
1. чек күчермәсе
2. сату-алу килешүе күчермәсе (булган очракта)

| | | |
|---|---|---|
| _________________ | _________________ | _________________ |
| *(дата )* | *(имза)* | *(сатып алучының ФИОсы)* |